Tenishev, E. R. (1996). *Rodoslovnaia Tenishevykh* [The Tenishevs' Pedigree]. Rossiiskaia provintsiia XVIII-XX vv. Kn. 1. Penza, pp. 397–401. (In Russian)

Tenishev, E. R. (1976). *Stroi salarskogo iazyka* [The Structure of the Salar Language]. 575 p. Moscow. (In Russian)

Tenishev, E. R. (1976). *Stroi saryg-uigurskogo iazyka* [The Structure of the Saryg-Yugur Language]. 307 p. Moscow. (In Russian)

Tenishev, E. R. (1995). *U tyurkskikh narodov Kitaia* [Among the Turkic Peoples of China]. (Dnevniki 1956-1958 gg.). 240 p. Moscow. (In Russian)

Tenishev, E. R. (1977). *Funktsional'no-stilisticheskaia kharakteristika drevneuigurskogo literaturnogo iazyka* [Functional and Stylistic Characteristics of the Ancient Uigur Literary Language]. Sotsial'naia i funktsional'naia differentsiatsiia literaturnykh iazykov. Pp. 61–78. Moscow. (In Russian)

Tenishev, E. R. (1987). *Iazyk proizvedenii Davletmukhammeda i Makhtumkuli Fragi* [The Language of Works by Davletmukhammed and Makhtumkuli Fraghi]. Sushchnost' razvitie i funktsii iazyka. Pp. 196–202. Moscow. (In Russian)

Tenishev, E. R. (1979). *Iazyki drevne- i srednetiurkskikh pamiatnikov v funktsional'nom aspekte* [Languages of Ancient and Middle Türkic Monuments in the Functional Aspect]. Voprosy iazykoznaniia, No. 2, pp. 80–90. (In Russian)

# КҮРЕНЕКЛЕ ТЮРКОЛОГ-ГАЛИМ ӘДҺӘМ РӘХИМ УЛЫ ТЕНИШЕВНЫҢ ТӨРКИ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

**Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
fanuzanurieva @yandex.ru.

Мәкалә дөньякүләм танылган галим, төрки тел белеменең иң күренекле шәхесләреннән берсе Әдһәм Рәхим улы Тенишевның (24.04.1921-11.07.2004) төрки һәм татар әдәби теле тарихы өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнүгә багышлана. Галимнең хезмәтләре, лингвистик фикере хәзерге тел белеме теориясенә һәм татар тел гыйлеме үсешенә керткән өлеше яктылыгында анализлана.

Ә.Р. Тенишевның борынгы төрки язма истәлекләр, Үзәк Азия халыкларының хәзерге телләре, чагыштырма-тарихи грамматика, төрки телләр тарихын өйрәнү өлкәсендәге тикшеренүләренә гомуми күзәтү ясалды. Төрки телләрнең тарихын чагыштырма планда тикшергән алты томнан торган күмәк хезмәтнең бу юнәлештәге эшчәнлегенең төрки халыкларның бай мирасын өйрәнү, аерым төрки телләрнең тарихи үсеш-үзгәрешен билгеләү ягыннан әһәмияте күрсәтелде. Мәкаләдә Ә.Р. Тенишевның дөнья фәне казанышларына таянып, төрки әдәби тел тарихы фәнен нигезләгән гомумтеоретик карашлары барланды, әдәби телнең вазифасын барлыкка китерә торган билге-шартлар тәфсилле анализланды. Галимнең хезмәтләренең хәзерге татар әдәби тел тарихын язу өчен фәнни-методик яктан зур мөмкинлекләр ачуы, алар нигезендә күп мәсьәләләрне аңлату, җавап табу мөмкинлекләре билгеләнде.

**Төп төшенчәләр:** Әдһәм Рәхим улы Тенишев, тюркология, татар теле, төрки телләр, әдәби тел тарихы.

## Кереш

Тел гыйлемендә халыкның тарихы һәм мәдәнияте белән тыгыз бәйләнештә торган тел тарихы фәне яшәп килә. Филологиядә 1960-1970 нче елларда тел тарихының бер тармагы буларак, әдәби тел тарихы дип аталган яңа фән юнәлеше формалаша. Төрки тел белемендә әдәби тел тарихы фәнен теоретик нигезләүче булып Ә.Р.Тенишев тора. Әдһәм Рәхим улы 40 ел дәвамында алтаистик эзләнүләр үзәге булган Мәскәү шәһәрендә Россия фәннәр академиясенең Тел белеме институтында төрки һәм монгол телләре бүлеген җитәкләгән, Россиянең мәшһүр галиме, дөньякүләм танылган тюрколог. Ә.Р. Тенишевның хезмәтләрендә урын алган әдәби тел тарихын үзенә якын фән тармакларыннан – тарихи грамматикадан аерып торган сыйфатларын, әдәби телнең табигатен һәм вазифаларын билгели торган төп фәнни принципларын ачыклау эшебезнең актуальлеген тәшкил итә.

Чыннан да, халыкларның тарихлары икътисад үсешендә, сәяси вакыйгаларда гына түгел, гасырлар дәвамында тудырылган күпсанлы һәм кыйммәтле мәдәни мирасында да. Ә.Р.Тенишев ачыклаган төрки әдәби телнең асыл табигатен барлыкка китерә торган билгеләрне: эшкәртелгән, норма һәм функциональ-стилистик вариантлылыкка ия булу, традициясе-дәвамчанлыгы күренешләрен әдәби ядкарьләр үрнәгендә яктырту эшебезнең максаты булып тора. Галимнең киңкырлы эшчәнлеге В.И. Кирсанов [Кирсанов, 1980, б. 3-25], А.В. Дыбо [Дыбо, 2001, б. 6-18], Д.М. Насилов [Насилов, 2006, б. 6-12], И.Б. Бәширова [Бәширова, 1999, б. 37-38], Ф.Ш. Нуриева [Нуриева, 2001, б. 18-22; 2004, б. 19-45] хезмәтләрендә яктыртылса да, Ә.Р. Тенишевның төрки әдәби тел тарихы өлкәсенә караган эшчәнлегенә махсус игътибар ителмәде. Мәкаләбездә Әдһәм Рәхим улы Тенишевның әдәби тел тарихын өйрәнүдә ирешкән казанышларын барлап, аларның татар әдәби тел тарихын өйрәнүдә, үсеш-үзгәрешен, вариантлылыгын билгеләүдә кулланылу мөмкинлекләрен билгеләү эшебезнең яңалыгын тәшкил итә. Ә.Тенишев мәкаләсендә әдәби тел тарихының үз фәненә хас метод-алымнар белән тикшерелергә тиешлеген күрсәтеп, бер генә төрки телнең дә бу нигездә өйрәнелмәве хакында фикер әйтелгән иде [Тенишев, 1988, б. 44]. Бүгенге көндә иске татар телендә язылган

барлык чыганаклар да диярлек галимнәр тарафыннан тикшерелгән, фәнни әйләнешкә кертелгән. Соңгы ике дистә ел эчендә Ә.Р.Тенишевның теоретик фикерләренә, фәнни методикасына нигезләнеп, татар әдәби тел тарихын өйрәнгән И.Б. Бәширова [Бәширова, 1999], Ф.Ш. Нуриева [Нуриева, 2004], коллектив хезмәт [Татар әдәби тел тарихы, 2015, 2017] һәм башка галимнәрнең монографияләре нәшер ителде. Әлеге хезмәтләрдә язма традициянең, норманың саклану дәрәҗәсе ачыкланган, иске татар әдәби теленең үсеш-үзгәреше һәм әдәби телнең җирле вариантлары тикшерелгән.

Хезмәтне язу барышында түбәндәге анализ ысуллары кулланылды: галим хезмәтләрендә китерелгән фактларны табу гомумлингвистик тасвирлау һәм барлау ысулына нигезләнде; чорга бәйле әдәби нормаларны, әдәби тел вариантларын чагыштырганда, чагыштырма-тарихи метод кулланылды.

**Төп өлеш. Галимнең тормышы һәм фәнни эшчәнлегенә кыскача күзәтү**

Тыңгысыз, киң колачлы галим Әдһәм Рәхим улы Тенишев үзенең чыгышы белән XV-XVI гасырларда яшәгән кенәз Тенишевлар нәселенә барып тоташа. Бу кенәзлекнең күп кенә оныклары тора-бара христиан динен кабул итә, ә Ишмөхәммәт буыныннан килгәннәре һәм алардан туган Шөкер-Али тармагы мөселман динендә кала. 1921 елның 24 апрелендә Пенза шәһәрендә дөньяга килгән Әдһәм Рәхим улы шул Шөкер-Али тармагыннан. Татар кенәзләре элек-электән хәрби хезмәттә батырлык күрсәткәне һәм фәндә уңышлы эш башкарганнары өчен хөкүмәттән бүләк алганнар. Мәсәлән, патша Василий Иванович Тениш Кугушевка зур җир биләмәләре биргән. Бу җирләр соңыннан аларның уллары Еники Ямашка һәм Исәшкә күчкән. Атаклы татар язучысы Әмирхан Еники шушы тармактан, алар – Әдһәм Тенишев белән нәселдәшләр. Ишмөхәммәт һәм Еники нәселеннән яңа дәвергә байтак күренекле талант ияләре үсеп чыккан. Мәсәлән, Колынчык Еникиев – атаклы рус язучысы А.И. Купринның бабасы. Ишмөхәммәт нәселенең Пенза төбәгендә яшәгән ундүрт буыны билгеле. Бу нәсел татар дөньясына билгеле дин галиме Муса Бигиевне, язучы Заһир Бигиевне, татарның беренче революционерларының берсе, язучы Гафур Коләхмәтовны бирүе белән дә билгеле [Тенишев, 1996, б. 397-401; Нуриева, Курбатов 2003, б. 46-47].

Булачак галим татар мәдәниятен үстерүгә үзләреннән зур өлеш керткән, белемне югары бәяләгән гаиләдә тәрбияләнә, шәхси китапханәләрендәге гарәп, фарсы, рус китапларын, гарәп графикасы белән язылган борынгы кульъязмаларны укып-тыңлап үсә. Әдһәм Тенишевның әтисе Рәхим Мөбин улы һәм әнисе Әминә Алим кызы шулай ук татар мәдәниятен үстерүгә күп көч салган фидакяр затлар була. Әтисе Казан реаль училищесында белем алган, татар халкының танылган шәхесләре Г.Тукай белән аралашкан, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Г.Коләхмәтовлар белән татар спектакльләре уйнаган. Галимнең әбисе Хәбибҗамал абыстайга танылган дин галиме Ризаэддин Фәхретдинов “Мәшһүр хатыннар” китабында аерым бүлек багышлаган [Нуриева, 2001, б. 19].

Морзалар нәселеннән чыккан, югары белем һәм тәрбия алган әти-әнисенең, якыннарының үз акыл-көчен халыкка хезмәт итүгә багышлаганын күреп үскән Әдһәм Рәхим улының күп сыйфатлары гаилә үрнәгеннән килә булыр. Гомерен төрки телләрне өйрәнүгә багышлау фикере кайчан тугандыр – монысы безгә билгесез, ләкин мәктәпне тәмамлап, техник юлны сайлаган Әдһәм Рәхим улы урау юллар үтеп, 1941 нче елда Ленинград университетының шәрык телләре факультетына укырга керә, аны 1945 нче елда тәмамлый, төрки телләр белгечлеге ала. Аның укытучылары – дөньяга мәшһүр галимнәр Н.К. Дмитриев, А.Н. Кононов, Е.Э. Бертельс, И.Ю. Крачковский була. Әдһәм Рәхим улының фәнни эшчәнлегендә якташыбыз, бөек галим С.Е. Маловның зур роль уйнаганын аерып әйтергә кирәк. 1953 нче елда ул С.Е. Малов җитәкчелегендә борынгы уйгыр язма әдәби тел истәлеге “Алтун Ярук” буенча кандидатлык диссертациясен яклый. Яшь белгеч 1954 елда Мәскәү шәһәрендә урнашкан СССР Фәннәр академиясенең Тел белеме институтына эшкә билгеләнә. Бераздан (1956 ел) Кытай Фәннәр академиясе соравы буенча төрки тел белгечләре әзерләү өчен өч елга Кытайга җибәрелә. Бу чор эшчәнлеге бик интенсив, киң колачлы бара. Ул төрек теле укыта, төрки телләр белгечләре – аспирантлар әзерләүгә җитди игътибар бирә. Соңыннан аның укучылары зур галимнәр булып китәләр. Аның төрки телләрне өйрәнүгә багышланган ике китабын кытай теленә тәрҗемә итеп бастырып чыгаралар. Читтә эшләгән вакытта ул Тибетның төрки халыклар яшәгән өлкәләрендә җанлы сөйләмне өйрәнү өчен фәнни сәфәрләргә чыга, җентекле язмалар-көндәлек алып бара.

1959 елда Мәскәүгә кайткач, Кытайдагы эшчәнлеге нәтиҗәсендә Синьцзян, Цинхай, Ганьсу төбәкләрендә тупланган экспедиция материалларын эшкәртеп бастырган күпсанлы мәкаләләре, ике китабы дөнья күрә. Әдһәм Тенишев – салар төркиләре тарихын фәнни дәрәҗәдә беренче булып өйрәнгән галим. 1969 елда ул салар теленнән туплаган материаллары нигезендә "Строй саларского языка" дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклый. Хезмәттә бу көнгә кадәр уйгыр, төрекмән телләренең бер диалекты итеп каралган салар теленең мөстәкыйль тел булуы исбатлана, киң яссылыкта тарихи, этногенетик, чагыштырма-лингвистик материаллар белән раслана. 1976 елда әлеге хезмәт аерым китап булып басыла. Яшь профессорның 1976 елда "Строй сарыг-югурского языка" монографиясе дә нәшер ителә, беренче бүлектә сары уйгырларың, икенче бүлектә шира уйгырларның телләре, фонетикасы һәм сүзлеге Ә. Тенишевка хас төгәллек белән эшләнгән [Тенишев, 1976 (Строй...]. Әдһәм Рәхим улының фәнни тикшерүләренең яңалыгы һәм тирәнлеге әһәмиятле булган кебек, алдагы буын тикшерүчеләр өчен диалектны аерып чыгару принципларын һәм критерийларын билгеләве белән хезмәт аеруча кыйммәтле. Аның Кытайда эшләү дәверендә алып барган этнографик материалларга бай көндәлеге кырык елдан соң нәшер ителде [Тенишев, 1995].

1963 нче елда Россия Фәннәр академиясенең Тел институтына төрки телләр бүлегенең мөдире итеп билгеләнгәч, Әдһәм Рәхим улы бөтен гыйльми мәсьәләләрне барлап, үзенең мәсләктәшләре белән бергә коллектив хезмәтләр язуны максат итеп куя. Аның фәнни һәм административ җитәкчелегендә дөньякүләм әһәмияткә ирешкән алтаистика, бигрәк тә, төрки телләрне чагыштырма-тарихи юнәлештә өйрәнгән фундаменталь хезмәтләр нәшер ителә башлый. Галим куйган бурычларның киң һәм күпкырлы булуы, күтәрелгән мәсьәләләрнең фәнни тирәнлеге һәм яңалыгы Әдһәм Рәхим улы Тенишевка тюркология фәненең мәшһүр галиме данын китерә. Киң гыйльми фикерле Әдһәм Рәхим улы - шул белемен, мәгълүматын башкаларга өләшүче кешелекле һәм могтәбәр зат бүлек белән 40 ел җитәкчелек итә, җылы фәнни мохит булдыра. Ул җитәкләгән төрки һәм монгол телләре бүлегендә төрки телләрнең этимологик сүзлеге әзерләнә һәм бастырыла башлый, "Дөнья телләре" программалары кысаларында "Төрки телләр" дигән энциклопедик томлык әзерләнә һәм бастырып чыгарыла (ул аның баш мөхәррире һәм күп кенә мәкаләләрнең авторы [Языки мира, 1997]. Ә.Р. Тенишев остазы Н.К. Дмитриевның фәнни мирасын лаеклы дәвам итүче, тәҗрибәле җитәкче буларак бәяләнә [Дыбо, 2001, б. 6-18]. Төрки тел фәненең казанышларына таянып, борынгы төрки тел күренешләрен реконструкцияләү каралган "Төрки телләрнең тарихи-чагыштырма грамматикасы" дип аталган алты томлыкның программасы төзелеп, бүлек галимнәре белән аерым томнарны әзерләү һәм бастыру юнәлешендә нәтиҗәле эш алып барыла. Хезмәтнең беренче дүрт томы ("Фонетика" [Сравнительно-историческая грамматика, 1984], "Морфология" [Сравнительно-историческая грамматика, 1989], "Лексика" [Сравнительно-историческая грамматика, 1997; 2001]) галимнең турыдан-туры катнашлыгында дөнья күрә. Әдһәм Тенишев авторларны оештырып, фикер уртаклыгына ирешеп кенә калмый, аерым бүлекчәләрне дә яза. Әлеге томнарда чагыштырмалы-тарихи ысул кулланылып, иң борынгы төрки нигез тел реконструкцияләнә. Танылган галимә Ф.М. Хисамова сүзләре белән әйткәндә, "Хәзерге заман лингвистика фәне югарылыгында эшләнгән әлеге капиталь хезмәтләрнең чыгуы төрки телләр тарихын гомуми планда өйрәнү өчен генә түгел, ә аерым төрки телләрнең грамматик төзелешенә хас кайбер мәсьәләләрне дә яңача фәнни нигездә аңлатырга мөмкинлек бирә. Традицион тюркология фәнендә, мәсәлән, кыпчак төркеменә кергән телләр, шул исәптән татар теле дә, тарихи яктан күп кенә структур үзгәрешләр кичергән «яңа» телләрдән санала иде. Борынгы һәм иң борынгы төрки нигез телне яңача фәнни нигездә реконструкцияләү нәтиҗәләре күп кенә очракларда татар теленең борынгы нигез телгә шактый якын торуын дәлилләргә дә мөмкинлек бирә" [Хисамова, 2013, б. 33]. Грамматиканың өч томы басылып чыгу белән Әдһәм Тенишев Азия мөселманнар комитетының Әл-Бохари вакыфы бүләгенә лаек була. Бу хезмәтләрнең әһәмиятен бөтен шәрык дөньясы таный.

Грамматиканың бишенче томы "Региональные реконструкции" [Сравнительно-историческая грамматика, 2002] Ә.Р. Тенишев җитәкчелегендә һәм катнашы белән әзерләнә. Биредә тикшеренүләр хәзерге заман төрки телләре һәм диалектларын, шулай ук язма истәлекләрне генетик төркемнәр нигезендә торгызу юнәлешендә алып барыла. Хезмәттә аерым төрки телләрнең тарихы конкретлаштырыла, тарихи

үсеш вакытында аларның диалектлар системасының кисешүе яки таркалуы, үсеш-үзгәреше күрсәтелә, пратөрки (әүвәлге) чор төгәл торгызыла (реконструкцияләнә). Әмма галим тарихи грамматиканың соңгы – алтынчы “Пратюркский язык. Картина мира пратюрков” [Сравнительно-историческая грамматика, 2006] томының басылып чыгып, тюркология фәнен иң югары баскычка күтәргән хезмәт буларак бәя алуын күрергә өлгермәде. 2004 елның 11 нче июлендә бу дөньядан бакыйга күчте.

Тенишев Әдһәм Рәхим улы җитәкчелек иткән бүлектә төрки телләрдән тыш, монгол телләрен тарихи юнәлештә тикшерү, монгол теленең тулы сүзлеген төзү эшләренә игътибар ителә.

1977 елда Әдһәм Рәхим улы Тенишев халыкара ЮНЕСКО оешмасы карамагында булган Европа лингвистик атласының төрки телләр буенча җаваплы редакторы итеп билгеләнгәч, төрки диалектологиясен өйрәнү перспективасына бәйле мәкаләләре дөнья күрә. 1987 елда академик А.Н. Кононов вафатыннан соң, Россия тюркология комитеты җитәкчесе итеп раслана, Россия тюркология фәне үсешенең юнәлешен билгеләү, милли республикаларда кадрлар әзерләү, фәннең мөһим өлкәләрен колачлаган фәнни хезмәтләр яздыру, аларны нәшер итү, ел саен Тюркологик пленум җыю, гыйльми конференцияләр уздыру эшләре дә аның җаваплылыгына күчә. Тюркология фәнендә иң абруйлы “Советская Тюркология” журналы 1970 елның 1 апрелендә нәшер ителә башлаган. Фәннәр Академиясенең басма органы булган әлеге журналны җитәкләү дә аның җилкәсенә төшә. Тюрколог галим 1990 елда Россия культура фондында “Евразия халыклары дастаны” редакторы итеп билгеләнгәч, аның редакторлыгында кыргыз, карачай-балкар, карел-фин, бурят һәм башка бик күп халыкларның дастаннары нәшер ителә, дөньякүләм танылу ала. 1995 елда “Манас”ның 1000 еллыгы халыкара бәйрәменә аның өченче, дүртенче томнары әзерләп бастырыла. Әдһәм Рәхим улы Кырымда яшәүче төрки халыкларын – кырым татарлары, караим, кырымчак телләрен, аларның тарихын җентекләп өйрәнеп, саллы хезмәтләр бастыра.

Галимнең филология фәненең берничә зур тармагында алып барган фидакяр хезмәте дөньякүләм югары бәясен ала, Тенишев Ә.Р. 1982 елда Төрек Тел Курумуның Шәрәф иясе, “Фин-угыр җәмгыяте” әгъза-мөхбире итеп сайлана. 1998 елда Төркия дәүләт башлыгы Сөләйман Демирел галим Әдһәм Рәхим улы Тенишевны Likyat nişanı медале белән бүләкли.

**Әдһәм Рәхим улы Тенишевның төрки һәм татар әдәби тел тарихын өйрәнү өлкәсендәге эшчәнлеге.** Тирән белемле Әдһәм Рәхим улының фәнни эшчәнлеге күп өлкәләрне колачлый. Аның төп хезмәтләрен шартлы рәвештә дүрт юнәлешкә бүлеп карарга мөмкин: Үзәк Азия халыкларының хәзерге телләре, борынгы төрки язма истәлекләр, чагыштырма-тарихи грамматика, төрки телләр тарихы.

Мәкаләбездә галимнең фәнни юнәлешләреннән берсе – төрки язма әдәби истәлекләрен өйрәнү белән бәйле эшчәнлеген яктыртуга игътибар бирербез.

Тел белемендә XX гасырның 60-70 нче елларында телне структур һәм функциональ-стилистик яктан өйрәнү урын ала, тел нормаларының һәм стильләрнең төзелешен һәм үсешен өйрәнә торган тармак – әдәби тел тарихы фәне формалаша. Төрки тел белемендә әлеге юнәлешнең төп принципларын теоретик нигезләүче галим - Әдһәм Рәхим улы Тенишев. Телләрнең үсеш тарихын төгәл күз алдына китерү, гомуми һәм хосусый билгеләрен дөрес итеп аерып чыгару максатыннан, Ә.Р.Тенишев хезмәтләрендә төрки телләр тарихын өч юнәлештә өйрәнү мөмкинлеге билгеләнә: 1) милли телнең тарихи грамматикасы, 2) әдәби телнең тарихи грамматикасы, 3) әдәби тел тарихы. Әлеге юнәлешләр өйрәнүнең максаты, ысуллары һәм тикшерү өчен нигез булган чыганаклар буенча да бер-берсеннән шактый аерылып тора. Һәр юнәлештә тел берәмлекләренең үз системасын яшәтә торган, үзләренә генә хас булган бәйләнеш-мөнәсәбәтләре ачыкланган, төп өйрәнү принциплары билгеләнгән [Тенишев, 1988, б. 67-78]. Тарихи грамматикада халык теленең тарихы төзелеше буенча, ягъни структур яктан өйрәнелсә, әдәби тел тарихы фәне борынгыдан килгән һәртөрле язма истәлекләргә нигезләнеп, гомумтөрки телләр төркемендә яки конкрет бер телдә формалашу тарихын, әдәби телнең чорларга бүленешен, кулланылыш үзенчәлекләрен өйрәнә. Әдәби тел тарихында тел нормаларының һәм стильләрнең үсеш-үзгәреше тарихи-иҗтимагый вәзгыятькә бәйле рәвештә, ягъни функциональ юнәлештә тикшерелә. Әдәби тел тарихына мөнәсәбәттә тел элементларының кайсы төркем төрки телдән булганын гына түгел, язма әсәрдәге һәр лексик, морфологик һәм синтаксик чараларның текстта нинди функция үтәүләренә, матур

әдәбият текстында поэтик алымнарның кулланылуына, поэтик функциясенә игътибар итү мөһим. Максаты һәм юнәлешләре төрле булуга карамастан, халыкның тарихы һәм мәдәниятенә мөнәсәбәттә әдәби тел тарихы һәм тарихи грамматика бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тора. Шушы үзенчәлекне истә тотып, Әдһәм Рәхим улы Тенишев төрки телләр тарихын өйрәнгәндә, сөйләмә һәм язма әдәби телнең табигате һәм вазифасы һич тә бер үк төрле була алмавын, шуңа күрә язма әдәби тел тарихын үзенә аерым, сөйләм теленең структурасын шулай ук аерым тикшерү зарурлыгына аеруча игътибар итә. Борынгы язма истәлекләрдә чагылыш тапкан әдәби тел, кагыйдә буларак, сөйләм теле белән тәңгәл килми, чөнки истәлекләр телендә борынгы язма традицияләрнең дәвамчанлыгы саклана. Галимнең барлык хезмәтләрендә язма әсәрләрнең телен һәм гомуми тел төзелешен өйрәнгәндә, бу тармаклар тарихын берсен икенчесеннән аерып карарга кирәклегенә басым ясала [Тенишев, 1976 (О построении...), б. 230-232; 1988, б. 67-78].

Төрки әдәби телне башлап өйрәнгән тюркологлар В.В. Радлов, С.Е. Малов хезмәтләрендә төрки язма әдәби телне өйрәнүдә аның иҗтимагый табигате истә тотылса да, алга таба тикшеренүләрдә Әдһәм Рәхим улы әдәби телнең социаль-иҗтимагый һәм функциональ табигатенә игътибар ителмичә, текстның структур төзелешен тикшерүгә өстенлек бирелүен һәм әдәби телнең табигатен һәм вазифасын барлыкка китерә торган үзенчәлекләрнең объектив яктыртыла алмавын тәнкыйди билгеләп үтә.

Әдәби тел тарихы фәне үзенең теориясе, терминологиясе белән рус, славян, көнбатыш европа әдәби телләрен өйрәнүгә бәйле үсеш ала, дип күрсәтә галим. 1983-1986 нчы елларда нәшер ителгән инглиз, немец, француз әдәби тел тарихына бәйле хезмәтләрдә әдәби тел, әдәби норма төшенчәләрен аңлату методик һәм типологик яктан үрнәк була ала дигән фикере, безнеңчә, игътибарга лаек: «При изучении истории литературных языков совершенно необходима опора на сравнительно-типологический материал. Опираясь на фонд германских, французского, славянских языков, можно с уверенностью говорить, что тюркские литературные языки подчиняются тем же общим закономерностям сложения и развития, что и индоевропейские литературные языки. … Настало время рассматривать процессы развития под единым углом» [Тенишев, 2006, б. 44]. Әлеге эшнең мөһимлеген аңлап, хәзерге заман лингвистика фәне югарылыгында Ә.Р. Тенишев төрки һәм, шул исәптән татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләрен өйрәнүгә бәйле теоретик фикерләрен бәян итә.

Сөйләмә телдән аермалы буларак, язма әдәби тел иҗтимагый үсешнең билгеле бер этабында үсеш ала. Әдәби тел кануннары, нигездә, язу барлыкка килгән чор белән тыгыз бәйләнештә карала. Галимнең халык тарафыннан иҗат ителеп, буыннан-буынга күчеп килгән фольклор әсәрләрен әдәби телнең бер состав өлеше - элгәресе итеп өйрәнелергә мөмкинлеге хакындагы фикере, әдәби телнең кайбер мәсьәләләрен яңача аңлатырга мөмкинлек бирә [Тенишев, 2006, б. 44].

Әдәби телнең үсеше җәмгыятьтәге вакыйгалар белән аерылгысыз мөнәсәбәттә торуына нисбәттә, Ә.Р. Тенишевның әдәби телнең үсешен ике зур чорга: милләткәчә һәм милли чорларга бүлеп өйрәнүгә бәйле нәзари фикерен билгеләп үтәргә кирәк. Һәрбер чор үз эчендә тагын бүленеп, үсеш этаплары конкретлаштырылып тикшерелә. Бигрәк тә, беренче чорны өйрәнү катлаулы. Милләткәчә чорда, борынгыга таба киткән саен, язма әдәби тел һәм гомумхалык сөйләмә теле бер-берсеннән шактый нык аерыла. Әдәби телләрне өйрәнгән хезмәтләрендә тамырлары белән иң борынгы төрки язма әдәби телләргә барып тоташкан иске татар әдәби теленә зур игътибар бирелә. Әдәби телнең тарихын өйрәнә башлаганда, ди Ә.Р.Тенишев, мәдәният үсешенә этәргеч биргән тарихи-мәдәни вакыйгалар, шәһәрләр торышы, андагы тел ситуациясе, грамоталылык дәрәҗәсе, язучылар, галимнәр эшчәнлеге һәм башка әдәби тел үсешенә ярдәм иткән көчләргә игътибар итү аеруча мөһим [Тенишев, 1979, б. 80-90; 2006, б. 44]. Борынгы язма традицияләргә ия булган татар әдәби теленең катлаулы тарихын өйрәнү барышында Ә.Тенишевның нәзари фикерләре татар галимнәре хезмәтләрендә киң кулланылыш таба. Мәсәлән, соңгы елларда нәшер ителгән татар әдәби теле тарихын язган галимнәрдән И.Б. Бәширова [Бәширова, 1999], Ф.Ш. Нуриева [Нуриева, 2004], [Татар әдәби тел тарихы, 2015, 2017] хезмәтләре Ә.Р.Тенишевның фәнни-методикасына нигезләнеп башкарылган. Әлеге хезмәтләрдә конкрет бер чордагы иҗтимагый һәм икътисади шартлар, тел ситуациясе, әдәби тел статусы һәм кулланылыш дәрәҗәсе, традиционлык һәм яңалыгы билгеләнгән.

Төрле тарихи-иҗтимагый шартларга бәйле милләткәчә чордагы әдәби телләр бер географик төбәктән икенче төбәккә күчерелеп кулланылуын күрә алабыз, әдәби тел үзе формалашкан төбәктән еракта әдәби тел функциясен үти алган. Бу очракларда борынгы традицион тел үзенең асыл үзенчәлекләрен күпмедер дәрәҗәдә саклаган хәлдә әдәби телгә региональ, җанлы сөйләм теле үзенчәлекләре үтеп кереп, әдәби телнең диалекталь нигезе үзгәреш кичерә. Бу гайре табигый хәл түгел, тарихи шартларга бәйле рәвештә милли әдәби тел оешканчыга кадәр әдәби тел вазифаларын бөтенләй чит тел дә башкарырга мөмкин. Моңа дәлил итеп, Ә.Тенишев рус һәм славян телләре тарихында иске славян теленең тоткан урынын, немец теле үсешендәге латин теленең ролен күрсәтә [Тенишев, 1994, б. 31].

Галим әдәби тел тарихын тикшергәндә, аның үз функциясен башкара торган структурасы тулаем каралырга тиеш дип билгели һәм әдәби телнең асыл табигатен барлыкка китерә торган төп биш билге-шарты күрсәтелә: 1) эшкәртелгән-шомартылган, 2) функциональ-стилистик вариантлылык, 3) норма вариантлылыгы, 4) шивәләрдән өстен тору, 5) дәвамчанлыгы, традициягә ия булуы һәм тикшеренүләрдә шушы билгеләрнең һәр очракта исәпкә алынырга тиешлеге ассызыклана [Тенишев, 2006, б. 44]. Ә.Р.Тенишев шул билгеләргә нисбәттә борынгы төрки әдәби тел язма истәлекләрне, аерым алганда, Орхон-Енисей, уйгыр язмаларын, төрки халыкларның (татар, үзбәк, төрекмән, кыргыз, төрек һ.б.) ядкарьләрен өйрәнгән [Тенишев, 1976 (О наддиалектном...); 1981, 1987, 1989, 2006, б.226-238; 2011, б. 186-197]. “Борынгы төрки рун язулы истәлекләрнең калыплашуы хакында” [Тенишев, 1976 (О наддиалектном...)] дип аталган мәкаләсендә Ә.Р. Тенишев телнең шул чорда барлыкка килгән үзенчәлекле төренә – койнега игътибарын юнәлтә, ягъни сөйләшү теле төрки кабиләләрдә төрлечәрәк барса да, аларның язма әдәби формасы калыплашкан, диалект теленнән өстен икәнлеген күрсәтә. Идел буенда язылган, татар әдәби теленең чишмә башы саналган “Кыйссаи Йосыф” поэмасының телен җентекле тикшергән мәкаләләрендә әдәби телнең төп үзенчәлеген хасил иткән әлеге билге-шартларның үзенчәлекләре ачыкланган. “Поэманың теле дигәч, “поэтик телнең” үзен дә яки аның стиль үзенчәлекләреннән дә түгел, ә үз функциясен башкара торган тулаем әдәби телнең структурасын күзалларга кирәк. Әдәби тел ул – ярымдиалект, җирле диалектларга каршы куела торган тел формасы. Алар арасында әдәби тел иң югары, иң могтәбәрле форма булып санала” [Тенишев, 1987, б. 133-135; 1994, б. 31]. Ә.Р. Тенишев поэманың төп үзенчәлекләрен шушы төп биш билге яссылыгында тикшереп, “Кыйссаи Йосыф” теленең асылын, аның башка төрки телләр белән мөнәсәбәтен ачыклый.

Әдһәм Рәхим улы төрки язма әдәби телләрнең тарихын әдәби тел вариантлары кысаларында олы хезмәт язуга керешкән иде. Галим үзенең бу юнәлештәге максатын татар әдәби теле барышы мисалында башлады да. Татар теле аның өчен һәрвакыт изге туган тел булды. Татар әдәби теле тарихын өйрәнгән хезмәтләрендә Идел буенда формалашкан әдәби телнең ерак гасырларга - борынгы төрки чорларга барып тоташуын, традициондәвамчан, эшкәртелгән, төрле яссылыктагы нормаларга ия булуын билгеләп, татар халкының милли телен чагылдырган әдәби тел оешканчыга кадәр, аның берничә региональ вариантта кулланылуын аерып күрсәтте. Галимнең әлеге фикере, безнеңчә, иске татар әдәби телен тикшергәндә, аеруча игътибарга лаек. Ә.Р. Тенишев Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәрендә ике тел ташкынының – төркихәрәзм белән угыз телләренең үрелеп баруын күрсәтә, бу катнаш телнең шактый вакыт дәвамында татар теле мохитендә дә яшәп килүен дәлили. ‘Татар’ дигәч, мин Идел буе татарлары элементларын күбрәк алган (киңрәк алганда, кыпчак элементларын) күз алдында тотам, ди галим. Кол Галинең бу поэмасы бердәнбер әсәр булса, ниндидер очраклык турында сүз йөртергә мөмкин булыр иде. Әмма бу алай түгел. Шундый угыз теле белән катнаш телдә XIII-XIV гасырларга караган башка әсәрләр, мәсәлән, “Кисекбаш”, “Бәдәвам”, “Кыйссаи аук” һәм башкалар язылган. Ә.Р. Тенишев “Кыйссаи Йосыф”ның телен иске татар әдәби теленең җирле вариантларыннан берсе дип саный [Тенишев, 1994, б. 31; 2006, б. 282]. Ул угызлашкан әдәби тел вариантының Идел буенда бердәнбер түгеллеген, башка әдәби төре (вариантлары) булганлыгын билгели. Бу урында шуңа игътибар итәргә кирәк: Тенишев региональ вариантлылык дигәндә, милләткәчә чорда халык кулланган әдәби телнең берничә вариантта яшәве, һәр әдәби вариантның үз укучысы булуын билгели. Галим иске татар әдәби теленең милли телгә кадәр дүрт-биш, иске төрек, иске азәрбайҗан,

иске төрекмән әдәби телләре ике-өч варианттан торганлыгын искәртә. Әдһәм Тенишев иске татар әдәби теленең вариантлары нигезендә караханлы-уйгыр, төрки-хәрәзм, угыз-төрек, болгар, чагатай әдәби традицияләре һәм үз татар нигезендә формалашуын аңлата. Иске татар әдәби теленең барлык вариантларының уртаклыгының асылы аларны берләштергән татар теленең үз нигезе булуында дигән фикерен әйтә. Рабгузинең “Кыйсасел-Әнбия”, Әхмәт Ясәвинең “Хикмәт”ләренең караханлы-уйгыр әдәби тел традициясенә нигезләнгән булуын күрсәтә. Төрки-хәрәзм нигезе сакланган әсәрләргә Котбның “Хөсрәү вә Ширин”, Хәрәзминең “Мәхәббәтнамә” поэмаларының телен кертә. Болгар нигезендәге әдәби вариант буларак, Идел Болгарстанының XIII-XIV гасыр эпитафик язмалары билгеләнгән, чагатай әдәби традицияләренең күпсанлы иске татар әдәби ядкарьләр нигезендә ятуын билгели [Тенишев,1983, б. 25-31; 2000, б. 27-31; 2006, б. 282]. Әлеге әдәби тел вариантларының XX гасыр башына кадәр, халык телен чагылдырган әдәби тел формалашканчыга кадәр дәвам итүен, төрле әдипләрнең үзләренә охшаган вариантта иҗат итүен күрсәтә.

Ә.Р. Тенишев хезмәтләрендә әдәби телнең биш билгесенең берсе булган жанр-стиль вариантлылыгына да зур игътибар бирелә. Әдәби телне иҗтимагый куллану аның функциональ стильләр системасын булдыруга китерә. Мәсәлән, дини (фәлсәфи-дидактик) әдәбият, матур әдәбиятның аерым жанрлары, фәнни әсәрләр, эш кәгазьләре, идарә, уку-укыту эшенә караган һәм шәхси язышу үзенчәлекләре. Аның шулай төрле стильләрдә кулланыла алуы әдәби телне төрле яссылыктагы күренешләр (стратлар) – диалектлар, гади сөйләм күренешләре белән тыгыз мөнәсәбәттә карауны таләп итә. Борынгы уйгыр телен этрафлы өйрәнгән галим буларак, ул бу чорның функциональ-стилистик характеристикасына аерым мәкаләдә тукталып, бу чор стильләренең һәрберсенә (дини-дидактик, матур әдәбият, фәнни хезмәтләр, эш кәгазьләре, хатлар) аерым күзәтү бирә һәм үзенчәлекләрен ачыклый. Аларда тел стратлары төрлечә кулланыла алуына туктала: “Әдәби телдә милли (диалект) тел элементларының ныгып, урнашып калуы, беренче чиратта, аның стильләренә бәйле. Борынгы уйгыр телендә эш кәгазьләре стилендә һәм шәхси язышуларда милли тел (диалект) элементлары күбрәк чагылыш таба. Әмма эш кәгазьләрендә алар төрле дәрәҗәдә урын ала. Ул документның төренә бәйле: аренда шартнамәләрендә, васыятьләрдә, озак вакыт саклanyрга тиешле квитанцияләрдә диалектлар, ягъни җанлы сөйләм теле элементлары аз күзәтелә, стандартлык һәм норма таләбе азрак булганнарында еш очрый” [Тенишев,1979, б. 61-78; 2006, б. 187-202]. Телнең функциональ стратификациясе әдәби телнең төрле кулланылышын күздә тота. Шуңа бәйле әдәби телнең үсеш юлларын функциональ парадигмалар нигезендә өйрәнү максатка ярашлы һәм әдәби тел тарихын өйрәнгәндә, бу юнәлеш нигез итеп алынырга тиеш, дип билгели Ә.Р. Тенишев [Тенишев, 2006, б. 187-202].

**Нәтиҗә**

Тирән белемле Әдһәм Рәхим улының фәнни эшчәнлеге күп өлкәләрне колачлый: төрки һәм алтай телләренең чагыштырма-тарихи грамматикасы, тарихи грамматика, төрки телләрнең әдәби тел тарихы, фонетика, морфология, этимология, лексикология, фольклор һәм борынгы төрки язма истәлекләр теле, хәзерге һәм тарихи диалектология, лингвокультурология. Әдһәм Рәхим улының чагыштырма-тарихи юнәлештәге дөньякүләм әһәмиятле хезмәтләре гомуми тел теориясе, бигрәк тә, телләр берлеге теориясенә зур өлеш кертә. Тел белеме фәнендә Ә.Р. Тенишев яңа фән тармагын нигезләүче галим буларак, зур бәя алды. Галимнең төрки әдәби тел тарихы буенча теоретик концепцияләренә нигезләнеп, узган гасырның 70 нче елларыннан тюркологиядә яңа юнәлеш – төрки әдәби телләр тарихы фәне барлыкка килде. Татар теле аның өчен һәрчак изге туган тел булды. Аның татар әдәби теле тарихын өйрәнгән хезмәтләрендә Идел буенда формалашкан татар әдәби телен өйрәнүнең методологик принциплары билгеләнгән.

Әдһәм Рәхим улы төрки фәненең киләчәген кайгыртып яшәде, яшь галимнәрне үстерүгә, фәнни җитәкчелек итүгә аеруча зур әһәмият бирә иде. Әдһәм Рәхим улы Тенишев - 20 фән докторы һәм 30 фән кандидатының остазы. Аның аспирантлары һәм докторантлары арасында татар, башкорт, рус, төрек, казакъ, үзбәк, төрекмән, якут, уйгыр, бурят, калмык, каракалпак, карачай, балкар, азәрбайҗан, чуваш, кырым татарлары халкы, европа илләре вәкилләре бар. Галимнең шәкертләре фән өлкәсендә мөһим ачышлары белән танылып, үз юнәлешләрен булдырдылар һәм дәвамчыларын үстерәләр. Шулай да Әдһәм Рәхим улы туган милләте – татар галимнәренә үз кеше булды: фәнни җитәкче, рәсми бәяләүче, китапларының

фәнни мөхәррире - гомумән, остаз ул. Гыйлем мәйданында Ә.Р. Тенишевтан фатиха алган танылган татар галимнәре Ф.Й. Йосыпов, Ф.С. Хәкимҗанов, Г.Ф. Саттаров, Р.А. Йосыпов, Ф.С. Сафиуллина, Л.К. Бәйрәмова, Ф.Г. Гарипова, И.М. Низамов, Ф.Ш. Нуриева, Э.Х. Кадыйрова, Р.А. Закиров һәм башка бик күпләр үзләрен татар дөньясына армый-талмый хезмәт итүче, фәнни мәктәпләр барлыкка китергән шәхесләр итеп таныттылар. Әдһәм Рәхим улы Тенишевның фәнни мәктәбен үткән, мәрхәмәтле ярдәмен күргән галимнәрнең күңелендә остазларына карата чиксез хөрмәт, юксыну хисләре саклана. Башкортстан республикасының Фәннәр академиясендә шәрәфле академик Әдһәм Рәхим улы Тенишевның вафатыннан соң төрле елларда, төрле басмаларда дөнья күргән яки хәзергәчә нәшер ителмичә калган мәкаләләре тупланган өч томлык “Сайланма хезмәтләр” җыентыгы нәшер ителде [Избранные труды, 2006 (Книга первая); 2006 (Книга вторая); 2011]. Мәскәүдә, үзе эшләгән Россия Фәннәр академиясенең Тел белеме институтының урал-алтай бүлегендә, Казан федераль университетында һәм башка төрки дәүләт фән оешмаларында күренекле галимне хөрмәтләп, мирасын барлап, телләрне өйрәнүдә остазларына лаек фәнни казанышлары белән уртаклашу йөзеннән фәнни конференцияләр уздырыла.

### Йомгак өлеше

Төрки әдәби телләр тарихын өйрәнүнең яңа этабы күренекле тюрколог-галим, безнең хөрмәтле милләттәшебез Әдһәм Рәхим улы Тенишев җитәкчелегендә башлана. Әлеге этап галимнең фәнни кыйммәткә ия булган теоретик фикерләренә нигезләнеп, лингвистикадагы яңа казанышлар яктылыгында хезмәтләр язылу белән характерлана.

Әдәби тел табигате һәм вазифасы белән катлаулы күренеш тәшкил итә, аның лингвистик нигезе язма истәлекләрдә чагылыш тапкан традицияләр һәм иҗтимагый тормышта барган экстралингвистик факторларда чагылыш таба. Ә.Р.Тенишевның хезмәтләрендә төрки әдәби телне өйрәнү өчен нигез булып торган түбәндәге аспектларны аерып чыгардык:

1) Төрки телләр тарихын өч юнәлештә өйрәнү: а) милли телнең тарихи грамматикасы; б) әдәби телнең тарихи грамматикасы; в) әдәби тел тарихы.

2) Дөнья әдәби телләр үсешендә типологик охшашлык булу.

3) Әдәби тел кануннары язу барлыкка килгән чор белән тыгыз бәйләнештә каралу, фольклор әсәрләрен әдәби телнең бер состав өлеше - элгәресе итеп өйрәнелә алуы.

4) Язма әсәрләрнең теле һәм гомуми тел төзелеше тармакларын берсен икенчесеннән аерып карау һәм аерым фән тармакларында тикшерү.

5) Әдәби телнең асыл табигатен барлыкка китерә торган төп биш билге-шарты: 1) эшкәртелгән-шомартылган; 2) функциональ-стилистик вариантлылык; 3) норма вариантлылыгы; 4) шивәләрдән өстен тору; 5) дәвамчанлыгы, традициягә ия булуы.

Ә.Р.Тенишев тәкъдим иткән әдәби тел, аның табигатен һәм тарихын өйрәнүгә бәйле принциплар лингвистика фәнендә тулысынча кабул ителде һәм төрки әдәби тел тарихы, хосусан, татар әдәби теле тарихы фәне галимнең теоретик фикерләренә нигезләнеп өйрәнелә. Мәшһүр галим Әдһәм Рәхим улы Тенишевның эшчәнлеге Россия фәнендә, дөнья тюркологиясендә югары бәя алды, бәрәкәтле мирасы бүген дә төрки тел гыйлеменең академик югарылыгын билгели.

**Әдәбият**

*Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар әдәби теле: исем категорияләре һәм фигыль наклонениеләрендә әдәби норма, норма вариантлылыгы һәм функциональ – стилистик вариантлылык. Казан: КДТУ нәшр., 1999. 576 б.

*Дыбо А.В.* Эдхям Рахимович Тенишев // Языковые уровни и их анализ. Казань: Изд-во Татарского гос. гуманитарного института, 2001. 184 с.

*Кирсанов В.И.* Крупный востоковед-тюрколог // Исследование языка древнеписьменных памятников. Казань, 1980. 160 с.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золтоордынского периода.-Казань: Казан. Гос. ун-т, 2004. 376 с.

*Нуриева Ф.Ш.* Татар зыялыларының затлысы // Языковые уровни и их анализ. Казань: Изд-во Татарского гос. гуманитарного института, 2001. 184 с.

*Нуриева Ф.Ш., Курбатов Х.Р.* Тенишев та, Еники дә, Куприн да – якын туганнар // Татарстан. 2003. №8. Б. 46-48.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. М., 1997. 799 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. Т.4. 2-е изд., М.: «Наука» 2001, 822 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология. М.: “Наука”, 1988. 560 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина

мира пратюркского этноса по данным языка. Т.6. М.: «Наука», 2006. 908 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Региональные реконструкции. Т.5. М.: «Наука», 2002. 767 с.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Фонетика. Т.1. М., 1984. 484 с.

Татар әдәби теле тарихы (XIII гасыр - XX йөз башы). II т.: Морфология. Грамматик категорияләрнең структур-субстанциональ үзенчәлеге һәм функциональ-стилистик мөмкинлекләре: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык. Казан: ТӘҺСИ, 2017. 888 б.

Татар әдәби теле тарихы. (XIII гасыр - XX йөз башы) I том: Фонетика. Графика: язма традицияләр, норма һәм вариантлылык - Казан: ТӘҺСИ, 2015. 696 б.

*Тенишев Ә.Р.* Кыйссаи Йосыф поэмасының теле // Мирас. №1, 1994. Б. 30-31.

*Тенишев Э.Р.* Избранные труды. Книга вторая. Уфа: Гилем, 2006. 380 с.

*Тенишев Э.Р.* Избранные труды. Книга первая. Уфа: Гилем, 2006. 304 с.

*Тенишев Э.Р.* Избранные труды. Книга третья. Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2011. 256 с.

*Тенишев Э.Р.* К истории литературного языка и культуры татарского народа // Вестник АН РБ . – Т.5, 2000. №1. С. 27-31.

*Тенишев Э.Р.* Новый список Рабгузи // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. Казань, 1983. С. 25-31.

Тенишев Э.Р. О киргизском литературном языке в донациональный период // Вопросы языкознания, 1989. №5. С. 32-40.

*Тенишев Э.Р.* О наддиалектной природе языка караханидско-уйгурских письменных памятников // Типы наддиалектных форм языка. М., 1981. С. 266-277.

*Тенишев Э.Р.* О наддиалектном характере языка тюркских рунических памятников // Turcologica . М., 1976, С. 230-232.

*Тенишев Э.Р.* О наддиалектном характере языка тюркских рунических памятников // Turcologica. Л., 1976. С. 164-172.

*Тенишев Э.Р.* О построении истории народно-разговорного и литературного языков // Тюркологические исследования. М., 1976. С. 230-232.

*Тенишев Э.Р.* О языке поэмы «Кысса-и Йусуф» Кул Гали // Поэт-гуманист Кул Гали. Казань: Тат.кн. изд-во, 1987. С.133-137.

*Тенишев Э.Р.* Принципы составления исторических грамматик и истории литературных языков // Советская тюркология. 1988. №3. С. 67-78.

*Тенишев Э.Р.* Родословная Тенишевых. - Российская провинция XVIII-XX вв. Кн. 1. Пенза, 1996, С. 397-401.

*Тенишев Э.Р.* Строй саларского языка. М., 1976. 575 с.

*Тенишев Э.Р.* Строй сарыг-югурского языка. М., 1976. 307 с.

*Тенишев Э.Р.* У тюркских народов Китая. (Дневники 1956-1958 гг.). М., 1995. 240 с.

*Тенишев Э.Р.* Функционально-стилистическая характеристика древнеуйгурского литературного языка // Социальная и функциональная дифференциация литературных языков. М., 1977. С. 61-78.

*Тенишев Э.Р.* Язык произведений Давлетмухаммеда и Махтумкули Фраги // Сущность развитие и функции языка. М., 1987. С. 196-202.

*Тенишев Э.Р.* Языки древне- и среднетюркских памятников в функциональном аспекте // Вопросы языкознания, 1979. № 2. С. 80-90.

*Хисамова Ф.М.* Туган тел һәм милләт язмышы // Татарика. 2003. №1. Б. 23-35.

Языки мира: Тюркские языки. Бишкек, 1997. 543с.

# ВКЛАД ИЗВЕСТНОГО УЧЕНОГО-ТЮРКОЛОГА ЭДХЯМА РАХИМОВИЧА ТЕНИШЕВА В ИЗУЧЕНИЕ ИСТОРИИ ТЮРКСКОГО И ТАТАРСКОГО ЯЗЫКОВ

**Фануза Шакуровна Нуриева**,
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
fanuzanurieva @yandex.ru.

Статья посвящена описанию научного наследия в области истории тюркских литературных языков всемирно известного ученого, востоковеда-тюрколога Эдхяма Рахимовича Тенишева (24.04.1921 – 11.07.2004). Труды ученого анализируются с точки зрения современной истории лингвистической мысли и развития татарского языкознания. В статье дана общая характеристика научной деятельности Э. Р. Тенишева в области древнетюркских памятников, современных языков и их диалектов Центральной Азии, сравнительной грамматики тюркских языков и истории литературных языков тюркоязычных народов. Под руководством Э. Р. Тенишева в шеститомном труде по сравнительной грамматике были реконструированы

все языковые уровни, восстановлены исторические периоды развития отдельных групп тюркских языков. В статье показан вклад Э. Р. Тенишева в теорию изучения истории тюркских литературных языков, который, учитывая достижения современной типологии литературных языков, создал стройную схему последовательного развития тюркских литературных языков. Э. Р. Тенишеву принадлежит ряд статей, в которых выдвинуты методологические принципы исследования старотатарского литературного языка.

**Ключевые слова:** Эдхям Рахимович Тенишев, тюркология, татарский язык, тюркские языки, история литературного языка.